| МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ** _24.09.2021_ | Казан ш. | **БОЕРЫК** _1012-п__ |

**«Камский Бекон» ҖЧҖ Сосновый Бор ятмасында «Западный» су алу җайланмасының (1(15), 2(16), 3, 3а (17), 4, 4а(18), 5, 14 номерлы су алу скважиналары) һәм «Восточный» (12, 13 су алу скважиналары) санитар саклык зоналарын билгеләү турында**

Россия Федерациясе Җир кодексы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы федераль закон, «Су белән тәэмин итү чыганакларының һәм эчә торган су үткәргечләренең санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары, «Җир асты суларын пычранудан саклауга карата гигиена таләпләре. СП 2.1.5.1059-01» санитария кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 30 ноябрендәге 1316-п номерлы боерыгы нигезендә, 2014 елның 13 маендагы җир асты байлыкларыннан файдалануга ТАТ № 02098 ВЭ лицензиясен, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең дәүләт санитар-эпидемиология кагыйдәләренә һәм нормативларына туры килү турында 2020 елның 15 сентябрендәге №16.11.11.000.Т.001984.09.20 санитар-эпидемиология бәяләмәсен исәпкә алып, шулай ук «Камский Бекон» ҖЧҖ Сосновый бор кишәрлегендә ун су алу скважинасында санитар саклык зоналары проекты нигезендә **боерык бирәм:**

1.Әлеге боерыкның 1 нче кушымтасындагы чикләрдә, әлеге боерыкның 2 нче кушымтасы нигезендә, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының 2002 елның 26 февралендә расланган «Эчә торган су белән тәэмин итү чыганакларында һәм суүткәргечләрдә санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормаларына туры китереп, территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану режимы белән, «Камский Бекон»

ЖЧЖ Сосновый Бор ятмасында «Западный» су алу җайланмасының (1(15), 2(16), 3, 3а (17), 4, 4а(18), 5, 14 номерлы су алу скважиналары) һәм «Восточный» (12, 13 су алу скважиналары) санитар саклык зоналарын билгеләргә.

2. Хокукый тәэминат бүлегенә (А.И. Ткачук) әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Дәүләт теркәвенә алганнан соң, каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесенә әлеге боерык күчермәсен түбәндәгеләргә җибәрергә:

- «Камский Бекон» ЖЧЖ;

- «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» ФБУ филиалына, – санитар саклык зонасын билгеләү турындагы белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен;

- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына.

4. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә түбәндәгеләр буенча чаралар уздыруны тәкъдим итәргә:

«Камский Бекон» ЖЧЖ Сосновый Бор ятмасында «Западный» һәм «Восточный» су алу җайланмаларының санитар саклык зоналары чикләре, су алу скважиналарының санитар саклык зоналары чикләрендәге территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану кагыйдәләре һәм режимнары турында халыкка мәгълүмат җиткерүне оештыру турында;

- территорияләрне үстерүнең территориаль комплекс схемаларын, функциональ зоналаштыру схемаларын, җир корылышы схемаларын, районнарны планлаштыру проектларын һәм генераль планнарны эшләгәндә санитар саклык зоналарын билгеләү турындагы карарны исәпкә алуны оештыру турында.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать ресурслары
министрлыгының 2021 елның 24
сентябрендәге 1012-п номерлы
боерыгына 1 нче кушымта

**«Камский Бекон» ҖЧҖ Сосновый Бор ятмасында «Западный» су алу җайланмасының (1(15), 2(16), 3, 3а (17), 4, 4а(18), 5, 14 номерлы су алу скважиналары) һәм «Восточный» (12, 13 су алу скважиналары) санитар саклык зоналары чикләре**

«Камский Бекон» ҖЧҖ җир асты суларын хуҗалык-көнкүреш һәм житештерүне су белән тәэмин итү максатында төркемле ике: «Западный» һәм «Восточный» су алу җайланмалары ярдәмендә җир асты суларының Сосновый бор ятмасының җир асты байлыклары кишәрлегендә ала. Су алу җайланмалары арасындагы ераклык 1,5 км.

Эшли торган сигез: 1(15), 2(16), 3, 3а (17), 4, 4а(18), 5, 14 номерлы скважиналардан торган «Западный» су алу җайланмасы «Камский Бекон» ҖЧҖ дуңгызчылык комплексыннан 0,25 км көнбатыштарак һәм «Тополя» бакчачылык ширкәтеннән 0,1 км көньяктарак, Татарстан торак пунктыннан 0,6 км төньяк-көнчыгыштарак һәм Татарстан Республикасы Тукай районы Сосновый Бор торак пунктыннан 0,9 км көньяктарак урнашкан.

Су алу скважиналарының географик координатлары:

№ 1(15) - төньяк киңлектә: $55^{0}$37′53,05″, көнчыгыш озынлыкта: $52^{0}$36′38,36″;

№ 2(16) - төньяк киңлектә: $55^{0}$37′50,85″, көнчыгыш озынлыкта: $52^{0}$36′43,86″;

№ 3 - төньяк киңлектә: $55^{0}$37′54,65″, көнчыгыш озынлыкта: $52^{0}$36′46,93″;

№ 3а (17) - төньяк киңлектә: $55^{0}$37′50,90″, көнчыгыш озынлыкта: $52^{0}$36′38,06″;

№ 4 - төньяк киңлектә: $55^{0}$37′54,02″, көнчыгыш озынлыкта: $52^{0}$36′40,91″;

№ 4а (18) - төньяк киңлектә: $55^{0}$37′47,96″, көнчыгыш озынлыкта: $52^{0}$36′45,60″;

№ 5 - төньяк киңлектә: $55^{0}$37′51,98″; көнчыгыш озынлыкта: $52^{0}$36′46,31″;

№ 14 - төньяк киңлектә: $55^{0}$37′51,80″, көнчыгыш озынлыкта: $52^{0}$36′53,33″.

Эшли торган ике: 12, 13 номерлы скважиналардан торган «Восточный» су алу җайланмасы «Камский Бекон» ҖЧҖ машина-трактор паркыннан 0,076 км төньяктарак һәм Татарстан Республикасы Тукай районы Сосновый Бор торак пунктыннан 0,5 км көньяктарак урнашкан.

Су алу скважиналарының географик координатлары:

№ 12 - төньяк киңлектә: $55^{0}$37′54,80″, көнчыгыш озынлыкта: $52^{0}$38′14,57″;

№ 13 - төньяк киңлектә: $55^{0}$37′56,36″, көнчыгыш озынлыкта: $52^{0}$38′26,87″.

Санитар саклык зонасының беренче поясы астында урнашкан җир кишәрлегенең кадастр номеры: 16:39:000000:5609.

Санитар саклык зоналары өч пояс составына оештырыла: беренче пояс (катгый режимлы) су алу корылмасы урнашкан территорияне, барлык суүткәргеч корылмаларының һәм су үткәрү каналы мәйданчыкларын үз эченә ала. Икенче һәм өченче пояслар (чикләүләр пояслары) су белән тәэмин итү чыганагы пычрануын кисәтү өчен билгеләнгән территорияне үз эченә ала.

Санитар саклык зонасының I поясы.

Су үткәрә торган продуктив горизонтның яхшы якланган булуын исәпкә алып, «Западный» су алу җайланмасының (1(15), 2(16), 3, 3а(17), 4, 4а(18), 5, 14 номерлы скважиналар) һәм «Восточный» су алу җайланмасының (12, 13 номерлы скважиналар) санитар саклык зонасының беренче поясы чикләре кырый скважиналар авызыннан 30 метр аралыкта билгеләнә.

Санитар саклык зонасының II поясы

«Западный» су алу җайланмасының санитар саклык зонасындагы икенче поясы 1(15),2(16),3а(17),4а(18),3,4 номерлы скважиналар авызыннан 84 метрлы радиус белән һәм 5, 14 номерлы скважиналар авызыннан 103 метрлы радиус белән билгеләнә; «Восточный» су алу җайланмасыныкы – 12, 13 номерлы скважиналар авызыннан 103 метрлы радиуста.

Санитар саклык зонасының III поясы

«Западный» су алу җайланмасының санитар саклык зонасындагы өченче поясы 1(15),2(16),3а(17),4а(18), 3,4 номерлы скважиналар авызыннан 594 метрлы радиус белән һәм 5, 14 номерлы скважиналар авызыннан 727 метрлы радиус белән билгеләнә; «Восточный» су алу җайланмасыныкы – 12, 13 номерлы скважиналар авызыннан 727 метрлы радиуста.

Татарстан Республикасы Экология
һәм табигать ресурслары
министрлыгының 2021 елның 24
сентябрендәге 1012-п номерлы
боерыгына 2 нче кушымта

**«Камский Бекон» ҖЧҖ Сосновый Бор ятмасында «Западный» су алу җайланмасының (1(15), 2(16), 3, 3а (17), 4, 4а(18), 5, 14 номерлы су алу скважиналары) һәм «Восточный» (12, 13 су алу скважиналары) санитар саклык зоналары чикләрендә территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану режимы**

1. Санитар саклык зонасының беренче поясы буенча чаралар

1.1. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясе өслек агымын аннан читкә агызып җибәрү өчен планлаштырылган, яшелләндерелгән, коймалап алынган һәм сак белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Корылмаларга бара торган юллар каты өслекле булырга тиеш.

1.2. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясендә түбәндәгеләр рөхсәт ителми: биек кәүсәле агачлар утырту, төзелешнең су үктәрү корылмаларын эксплуатацияләү, үзгәртеп кору һәм киңәйтүгә турыдан-туры кагылышы булмаган барлык төрләре, шул исәптән төрле билгеләнештәге торбаүткәргечләр салу, торак һәм хуҗалык-көнкүреш биналары урнаштыру, кешеләрне яшәтү, агулы химикатлар һәм ашламалар куллану.

1.3. Санитар саклык зонасының беренче поясы территориясендәге биналар ташландык суларны көнкүреш яки эшчәнлек канализациясенең иң якын системасына яки санитар-саклык зонасындагы беренче пояcтан читтә икенче пояс территориясендәге санитар режимны исәпкә алып урнаштырылган җирле чистарту корылмалары станцияләренә агыза торган канализация белән җиһазландырылырга тиеш.

Искәрмәле очракларда, канализация булмаса, санитар саклык зонасының беренче поясы территориясе пычрануга юл куймый торган урыннарда урнашкан, нәҗесләрне һәм көнкүреш калдыкларын кабул итү өчен, аларны чыгарганда су үткәрми торган корылмалар төзелергә тиеш.

1.4. Санитар саклык зонасының беренче поясында урнашкан су үткәрү корылмалары скважина очлыклары һәм скважина авызлары, резервуарларның люклары һәм агызу торбалары һәм насосларга су тутыру җайланмалары пычрану мөмкинлеген калдырмауны исәпкә алып җиһазландырылырга тиеш.

1.5. Су алу корылмаларының барысы да су алу корылмасын проектлаганда һәм санитар саклык зонасы чикләрен нигезләгәндә каралган проект җитештерүчәнлегендәге су алу корылмасын эксплуатацияләгәндә фактик дебитның туры килүенә системалы тикшерү уздыру аппаратурасы белән җиһазландырылырга тиеш.

## 2. Икенче һәм өченче пояслар буенча чаралар

2.1. Сулы горизонтларны пычрату ихтималлыгы өлешендә куркыныч тудыра торган барлык искергән, эшләми торган, җитешсезлекләре булган яки дөрес эксплуатацияләнми торган скважиналарны ачыклау, цементлау яки торгызу.

2.2. Яңа скважиналар бораулау һәм яңа төзелешнең туфрак катламын бозуга бәйле эшләре дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәге белән мәҗбүри килештереп гамәлгә ашырыла.

2.3. Яраксызланган суларны җир асты су горизонтларына агызуны, каты калдыкларны җир астында урнаштыруны һәм җир асты байлыклары белән эшләр башкаруны тыю.

2.4. Ягулык-майлау материаллары, агулы химикатлар һәм минерал ашламалар складлары, сәнәгый агынтыларны туплау, шлам саклау җайланмаларын һәм җир асты суларын химик пычрату куркынычы белән аңлатыла торган башка объектларны урнаштыруны тыю.

Мондый объектларны санитар саклык зоналарының өченче поясы чикләрендә урнаштыру бары тик якланган җир асты суларыннан файдаланганда гына, сулы горизонты саклау буенча махсус чаралар үтәү шарты белән, геологик контрольлек органнары бәяләмәсен исәпкә алып бирелгән дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәгенең санитар-эпидемиология бәяләмәсе булган очракта гына рөхсәт ителә.

2.5. Файдаланыла торган сулы горизонтка турыдан-туры гидрологик бәйләнеше булган җир өсте суларын санитар саклаганда җир өсте суларын саклауга карата гигиена таләпләре нигезендә кирәкле чараларны үз вакытында башкару.

## 3. Икенче пояс буенча чаралар

2 нче бүлектә күрсәтелгән чаралардан тыш, җир асты су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарындагы икенче пояс чикләрендә түбәндәге өстәмә чаралар үтәлергә тиеш:

3.1. Рөхсәт ителми:

зиратлар, үләт базлары, урыннарда санитария шартларын яхшырту кырлары, фильтрлаштыру кырлары, тирес саклау урыннары, силос траншеялары, терлекчелек һәм кошчылык предприятиеләре һәм җир асты суларын микроб белән пычрату куркынычы тудырган башка объектларны урнаштыру;

ашламалар һәм агулы химикатлар куллану;

төп кулланудагы урманнарны кисү һәм үзгәртеп кору.

3.2. Торак пунктлар һәм башка объектлар территорияләрен санитар төзекләндерү чараларын үтәү (канализация белән тәэмин итү, су үткәрми торган ташландык су чокыры ясау, өслек суларын читкә агызуны оештыру һ.б.).